ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 511-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 511-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2293-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.А. Чубаров тарафыннан
кертелә

**«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) икенче өлештә «Оешмаларда эшләүче» сүзләрен «Эшләүче» сүзенә алмаштырырга;
2) өченче өлештә «Оешмаларда эшләүче» сүзләрен «Эшләүче» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Янгын куркынычсызлыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 97 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 октябрендәге 506-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба Федераль закон) туры китерү максатларында эшләнде.

Федераль закон белән, шул исәптән, затларны, алар хезмәт эшчәнлеген оешмаларда гына түгел, ә законнарда каралган башка төр эшчәнлекне дә гамәлгә ашыра, янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүгә бәйле мәсьәләләр төгәлләштерелгән.

Федераль законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, закон проекты белән «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына шундый ук үзгәрешләрне кертү күздә тотыла.

**«Янгын куркынычсызлыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы закон актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү законнарның үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башка законнар кабул итүне таләп итми.

**«Янгын куркынычсызлыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.